ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 500-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 500-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 23 ноябре
№ 2245-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 220ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I чөлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 2 пунктта «урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен» сүзләрен «федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктта «урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен» сүзләрен «федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлектәге $6^2$ һәм $6^3$ пунктларны өстәргә:

$6^2$) федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән килешү буенча Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын раслау;

$6^3$) федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органының ашыгыч чаралар куллану турындагы карарын килештерү;»;

2) 3 статьяның 3 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлектәге $1^1$ һәм $1^2$ пунктларны өстәргә:

«$1^1$) Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын эшләү;

$1^2$) урманчылык территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын эшләү һәм раслау;»;

б) $13^9$ пунктта «янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыру һәм урман янгыннарын сүндерү» сүзләрен «урман янгыннарын контрольдә тоту зоналарын билгеләү, урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү, урман янгыннарын сүндерү» сүзләренә алмаштырырга, «урман янгыннарын сүндерү» сүзләреннән соң «шулай ук ашыгыч реакция чараларын гамәлгә ашыру» сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү тәртибе**

1. Гражданнар үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләүне урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын гражданнар үз ихтыяҗлары өчен торгилар үткәрмичә генә төзелә торган (алга таба – үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату – алу шартнамәсе) сату-алу шартнамәләре нигезендә башкаралар.

2. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзергә теләгән граждан (алга таба – гариза бирүче) вәкаләтле органга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында гариза (алга таба – гариза) белән мөрәҗәгать итә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), аның яшәү урыны буенча теркәлүе турында белешмәләр, шәхесен таныклый торган документ белешмәләре;

2) чикләрендә урман утыртмаларын сату-алу күздә тотыла торган урманчылык исеме;

3) агачның таләп ителә торган күләме, аның сыйфат күрсәткечләре һәм аны әзерләү максаты.

3. Гариза язма рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге яисә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин.

4. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында гариза алган көннән алып 10 көн эчендә вәкаләтле орган үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында яисә мондый шартнамә төзүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм мөрәҗәгать итүчегә бу хакта гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хатта баш тартуның сәбәбе күрсәтелгән булырга тиеш.

5. Вәкаләтле орган үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарны түбәндәге очракларда кабул итә:

1) тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат булган документлартәкъдим ителсә;

2) агачның гаризада күрсәтелгән күләме әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән нормативлардан артып китсә;

3) граждан күрсәткән урманчылыкта гаризада күрсәтелгән таләп ителә торган сыйфат күрсәткечләренә ия агач күләмнәрен әзерләү өчен җитәрлек урман утыртмалары булмаса;

4) әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән сроклар үтәлмәсә.

6. Чикләрендә гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләүгә яраклы урман утыртмалары урнашкан урманчылыклар турында мәгълүмат вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә, әлеге Законның 1 статьясының 1 һәм 2 пунктларыннан тыш

2. Әлеге Законның 1 статьясының 1 һәм 2 пунктлары 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**
**АҢЛАТМА**

Закон проекты «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә һәм аның аерым нигезләмәләрен актуальләштерүгә юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 343-ФЗ номерлы Федераль закон белән урманнарны янгыннан саклауны камилләштерүгә һәм федераль ашыгыч реакция резервын җәлеп итүнең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелгән.

2024 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясе субъектларының югары вазифаи затлары тарафыннан Россия Федерациясе субъекты территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планнары раслана. Күрсәтелгән план Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы белән килешү буенча раслана.

Ашыгыч реакция чараларын куллану механизмы күздә тотыла, аерым алганда, ашыгыч реакция чараларын куллану турында Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы карары Россия Федерациясе субъектының югары вазифаи заты белән килешү буенча кабул ителә дип билгеләнә.

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган аерым вәкаләтләрне урман янгыннарын контрольдә тоту зоналарын билгеләү буенча вәкаләтләр белән тулыландыру күздә тотыла. Тиешле вәкаләтне Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагына беркетү күздә тотыла.

Башкарма хакимиятнең күрсәтелгән республика органы вәкаләтләренә шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын эшләүне, шулай ук урманчылык территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын раслауны кертү дә күздә тотыла.

Закон проекты тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сатып алу-сату килешүләре төзү турындагы нигезләмәләрне актуальләштерү күздә тотыла.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 20 июнендәге 1623-р номерлы боерыгы нигезендә дәүләт хезмәтенең атамасы аныклана (урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен торгилар уздырмыйча гына сату-алу килешүе төзү).

Моннан тыш, закон проекты дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын 15 көннән 10 эш көненә кадәр кыскартуны күздә тота.

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан республика территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын раслау, Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 3 февралендәге «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Үзагач әзерләү хокукы бирү һәм шәхси ихтыяҗлар өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре проектын әзерләү турында карар кабул итү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» ПУ-80 номерлы Указына үзгәрешләр кертү, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 12 февралендәге «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 38 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.